ISBN 978-5-298-02812-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2015



# Гыйлем эстәп[1], ерак юлга

Борын-борын заманда Бохара шәһәре янындагы Шәҗегъ дигән авылда бер ир белән хатын яшиләр иде. Алар бик тату торалар, матур гына гомер итәләр иде.

Көннәрдән бер көнне боларның игезәк ир балалары туды. Ата белән ана бик шатландылар. Балаларның берсенә — Әбүгалисина, икенчесенә Әбелхарис дип исем бирделәр.

Көннәр, атналар үтте, айлар, еллар да үтеп киттеләр, балалар дүрт яшькә җиттеләр. Аларны мәктәпкә укырга бирделәр.

— Укысыннар, белем алсыннар, кеше булсыннар, — диделәр.

Әбүгалисина үзенең үткенлеге, зирәклеге белән башка балалардан аерылып тора иде. Әбелхарис, Әбүгалисина белән игезәк булса да, бер ата, бер анадан туса да, зирәклек һәм булдыклылык ягыннан туганы шикелле үк түгел иде.

---

[1] *Гыйлем эстәп* — гыйлем алу нияте белән.



Әбүгалисина бик яхшы укый, укытучы ни генә әйтсә дә, бик тиз төшенеп ала, белгәнен бер дә онытмый иде. Шулай ук ул, укытучы сөйләгәннәр белән генә канәгатьләнеп калмыйча, яшьтән үк китаплар укуга бирелде. Шуңа күрә бик күп нәрсәләр белде. Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка яручы» бер бала иде.

Аның зирәклеге, сизгерлеге турында бик кызык сүзләр сөйлиләр. Ул вакытларда мәктәпләрдә, асларына киез салып, идәнгә тезләнеп укыйлар: парталар булмый. Әбүгалисинаның иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куялар, ә үзләре, Әбүгалисина нишләр икән дип, кызыксынып карап торалар.

Әбүгалисина мәктәпкә килә, урынына килеп утыра, аннары бер югары, бер түбән карап тора. Аңа сорау бирәләр:

— Нишләп алай карангалыйсың? — диләр.

Әбүгалисина:

— Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да бар, элеккечә түгел, — ди.

Шулай ул киез астына салынган бер бит кәгазьнең калынлыгын да сизгән, имеш, дип сөйлиләр.

Унике яшенә җиткәндә, Әбүгалисина инде бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитеште, төрле фәннәрдән үзе дә башкаларга сабак укыта башлады. Үзеннән күп зур балалар аннан дәрес алдылар.

Ул төшкә кадәр балаларга сабак укыты, төштән соң урамга чыгып, алар белән рәхәтләнеп уйнап йөрде. Аның бу гадәте кайбер кешеләргә бер дә ошамый иде. Аңа:

— Син шундый галим, шундый акыл иясе кешесең, никадәр балаларга сабак өйрәтәсең, белем бирәсең. Ә үзең надан балалар белән уйнап йөрисең, — диделәр.

Әбүгалисинаның моңа бер дә исе китмәде. Ул:

— Кешенең һәр яшендә үзенә күрә бер матурлыгы була, сабыйлыкның матурлыгы уен белән, — дип җавап бирде.

Тагын берничә ел үтеп китте. Әбүгалисина зур галим булып җитте. Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз

күрәштерерлек кеше калмады. Ләкин ул үзе моңа гына риза булмады, тагын да тирәнрәк белем алырга теләде. Туганы Әбелхарис белән бергәләп, гыйлем эстәргә, алар туган илләреннән еракларга китәргә уйладылар. Ата-аналарыннан түбәнчелек белән рөхсәт сорадылар:

— Кадерле атабыз, сөекле анабыз, — диделәр, — безнең юллар йөреп, илләр күреп, төрле җирләрдә булып, гыйлем аласыбыз, бу дөньяның серләренә төшенәсебез килә. Безгә рөхсәт бирегез, изге теләктә була күрегез...

Ата белән ана, балаларыннан аерылу бик кыен булса да, аларның яхшы теләкләренә каршы килмәделәр.

— Бездән рөхсәт, теләгән җирләрегезгә барыгыз, дөнья күрегез, белем алыгыз, шул белемнәрегез белән халыкка файдалы кешеләр булыгыз, — диделәр.

Ике туган юлга чыкты. Ата белән ана аларга уңышлар теләп озатып калдылар.

Көн бардылар, төн бардылар, күп юллар үттеләр, ерак җирләргә җиттеләр. Бик күп авылларда, шәһәрләрдә булдылар, төрле-төрле кешеләрне күрделәр, зур гыйлем ияләре белән күрештеләр. Шулай йөри торгач, бер шәһәргә барып керделәр. Аны карап йөри торгач, беркөнне зур гына базарга килеп чыктылар. Ни күрсеннәр, бер җирдә бик күп халык җыелган, уртада бер кеше нидер сөйли.

Әбүгалисина белән Әбелхарис халык җыелган җиргә бардылар. Теге кеше, халыкка карап, болай дип кычкыра иде:

— И җәмәгать! Тыңлагыз, ишетми калмагыз! Иртәгә мәгарә[1] ишеге ачыла. Кереп карарга теләсәгез, белем алырга теләсәгез, әзер торыгыз... Ләкин шуны аңлагыз: мәгарәдән

---

[1] *Мәгарә* — тау куышы.

